Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Альметьевского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
2020 ел, 5 октябрь

КАРАР
№ 7

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата керемнәре турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

2018 елның 10 августындагы № 8 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата керемнәре турында» Нигезләмәгәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфасына, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләменә карап, вазифа окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU ) һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга .

3. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ә.Газизов